ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 апрель, 2018 ел № 24/12

Яр Чаллы шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләре өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме премиясе күләмен һәм бирү тәртибен билгеләү турында

Шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге 21/13 санлы Карары белән раслагшан Яр чаллы шәһәре бүләкләре турында Нигезнамәгә таянып, Яр Чаллы шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең һөнәри үсешен стимуллаштыру максатында
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләре өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме премияләрен гамәлгә кую тәртибе хакында Нигезнамәне кушымтага нигезләнеп расларга.

2. Гамәлдән чыккан дип танырга:

1) Шәһәр Советының 2008 елның 25 декабрендәге Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре һәм балаларга өстәмә белем бирүучреждениеләренең педагогик хезмәткәрләре өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме премиясен гамәлгә кую һәм күләмен билгеләү тәртибе

турында» 37/6 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2009 ел, 02 гыйнвардагы 1-2 саннарында бастырылган;

2) Шәһәр Советының 2010 елның 26 маендагы «Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре һәм балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренең педагогик хезмәткәрләре өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме премиясен гамәлгә кую тәртибен билгеләү турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» № 50/11 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2010 ел, 11 июнендәге 109-111 нче саннарында бастырылган;

3) Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге «Шәһәр Советының 2008 елның 25 декабрендәге 37/6 санлы Карары белән расланган мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре һәм балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренең педагогик хезмәткәрләре өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме премиясен гамәлгә кую тәртибен билгеләү турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 21/17 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2012 ел, 03 октябрендәге 77 нче санында бастырылган.

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының мәгариф, мәдәният, милли мәсьәләләр, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев